**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Аксар авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№ 92** **«01» март 2023 ел**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Аксар авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 29 декабрендәге 18 номерлы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 05 декабрендәге 512-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районының Аксар авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Аксар авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1.«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Аксар авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 29 декабрендәге 18 номерлы Зәй муниципаль районы Аауксар авыл җирлеге Советы карарына (Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге Советының 2021 елның 05 маендагы 32 номерлы, 2022 елның 01 апрелендәге 55 номерлы, 2022 елның 22 ноябрендәге 76 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәя нитәргә:

«5.6. Аукционда катнашу өчен дәгъва итүче түбәндәге күләмдә алдан акча (задаток) кертә:

100 миллион сумм һәм аннан да күбрәк сумманы тәшкил иткән муниципаль мөлкәтне сату турында мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән башлангыч бәянең 20 процентын;

100 миллион сумнан кимрәк тәшкил иткән муниципаль мөлкәтне сатутурында мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән башлангыч бәянең 10

процентын.»;

1.2. Түбәндәге эчтәлекле 5.6.1 пунктын өстәргә:

«5.6.1. Мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән счетка алдан акча (задаток) кертүне раслый торган документ буллы пшушы счеттан өземтә тора.»;

1.3.6.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәя нитәргә:

«6.3. Аукционда катнашу өчен дәгъва итүче түбәндәге күләмдә алдан акча (задаток) кертә:

100 миллион сумм һәм аннан да күбрәк сумманы тәшкил иткән муниципаль мөлкәтне сату турында мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән башлангыч бәянең 20 процентын;

100 миллион сумнан кимрәк тәшкил иткән муниципаль мөлкәтне сату турында мәгълүмати хәбәрдәк үрсәтелгән башлангыч бәянең 10 процентын.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлек торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз көчемдә калдырам.

Совет рәисе Ю.И.Гыйлманов